РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район, д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы, Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
19.10.2022

КАРАР
№ 16

Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче апрелендә кабул ителгән 10 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2022 №881 карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 28.04.2018 елның №10 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карары белән расланган айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга.

2. 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 28.04.2018 елның №10 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карары белән билгеләнә торган,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең вазыйфа окладларын күләмен 1,04 тапкырга арттырырга.

3. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәрен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл

җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфа оклады күләмен 1,04 тапкыр индексацияләү һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләү.

4. Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» нең 28.04.2018 елгы №10 карарына (Советның 09.11.2020 елгы №13 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең 11 958 сум күләмендә вазыйфаи окладын расларга.»;

4.2. 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2022 елның 1 октябреннән башлап, яңа штат расписаниеләрен расларга.

6. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге карарның гамәлен 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/artash адресы буенча урнаштырырга.

Арташ авыл
җирлеге башлыгы А.Р.Әгъләмҗанов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 2022 елның 19 октябрендәге 16 номерлы карарына 1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаларның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 16390 |
| Депутатлар | 11 958 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11 958 |